**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 гыйнвар № 44

г. Казань

Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елны FIFA конфедерацияләре кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 7 июнендәге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешне тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\44.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 31 гыйнвар, 44 нче
карары белән расланды

Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елны FIFA конфедерацияләре кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 7 июнендәге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлеш нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Тәртипнең максаты – башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү.

Бушлай йөрү дигәндә түләү алмыйча йөрү күздә тотыла.

3. Спорт ярышлары тамашачылары өчен бушлай йөрү хокукы Казан шәһәрендә уза торган спорт ярышлары матчларын үткәрү чорында бирелә:

спорт ярышлары матчлары үткәнгә кадәр бер көн алдан, спорт ярышлары матчлары үткән көндә һәм спорт ярышлары матчлары үткән көннән соңгы көндә спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында;

спорт ярышлары матчлары үткән көндә һәм спорт ярышлары матчлары үткән көннән соң килүче тәүлекнең 00:00 сәг. алып 04:00 сәг. кадәр спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда.

4. Волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затлар өчен спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында  бушлай йөрү хокукы Казан шәһәрендә спорт ярышларының беренче матчы үткән көнгә кадәр 10 көн алдан башланган һәм спорт ярышларының соңгы матчы үткән көннән соң 5 көннән соң тәмамланган чорга бирелә.

5. Әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлары булганда, спорт ярышлары тамашачыларына, волонтерларга һәм FIFA исемлегенә кертелгән затларга бушлай йөрү хокукы йөрү саны буенча чикләүләрсез бирелә.

6. Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспорты (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспорты, метрополитен, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспорты спорт ярышлары маршрутларын, аэропортлар һәм спорт ярышлары матчлары үткәрелә торган торак пунктлар арасында транспорт элемтәсен тәэмин итә торган спорт ярышлары маршрутларыннан тыш, «Россия-2018» оештыру комитеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы һәм «Россия Федерациясендә 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионатының транспорт дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы белән килештереп, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы билгели.

7. Спорт ярышлары маршрутлары буенча автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукы бирү шартлары түбәндәгеләр:

спорт ярышлары тамашачылары өчен – Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы раслаган тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән персональләштерелгән тамашачы картасы һәм матчка керү билеты яки билет күрсәткән көндә Казан шәһәрендә матчларны үткәрү көнендә стадионга керүне рөхсәт итә торган, FIFA раслаган спорт ярышларының билет сәясәте нигезендә сатып алынган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча матчка керү билетын алуга хокук бирә торган документ (билет);

волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затлар өчен – «Россия-2018» оештыру комитеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы раслаган аккредитация буенча нигезләмә нигезендә рәсмиләштерелгән аккредитация картасы.

Югарыда әйтеп кителгән документларның берсе дә булмаса, бушлай йөрү хокукы бирелми.

Юлда йөрү өчен түләүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы затка карап тикшерү өчен кирәкле документларны күрсәткәндә генә транспорт чарасына утыруга рөхсәт бирелә.

Юлда йөрү өчен түләүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы затлар спорт ярышлары тамашачылары, волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затлардан юлда йөргән өчен түләүне таләп итәргә яисә, әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән бушлай йөрү хокукы бирә торган документлар булмаган очракта, юлда йөртү хезмәте күрсәтүне туктатырга хокуклы.

8. Спорт ярышлары тамашачылары, волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затларга спорт ярышлары маршрутлары буенча автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында транспорт хезмәте күрсәтү «Автомобиль транспорты һәм шәһәр

җир өстендәге электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өстендәге электр транспорты белән пассажирлар һәм багаж йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 14 февраль, 112 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Спорт ярышлары тамашачылары, волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затларга спорт ярышлары маршрутлары буенча автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында багаж өчен түләү Татарстан Республикасы башкарма комитетының тарифларны җайга салу өлкәсендә вәкаләтле органы билгеләгән пассажирларга юл йөрүгә һәм багаж алып баруга чик максималь тарифлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Әлеге тәртиптә каралмаган вакыйгалар килеп чыкканда спорт ярышлары тамашачылары, волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затларга җанатарларны яклау үзәгенә мөрәҗәгать итәргә.

---

F:\KARAR\2017\44.docx